**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 19 октябрь | № 760

г. Казань

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Тойгелде интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең исемен үзгәртү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Тойгелде интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе исемен «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Түбән Табын интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә (алга таба – Учреждение) үзгәртү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 30 көн эчендә Учреждениенең гамәлгә кую документларына тиешле үзгәрешләрне кертергә.

3. Дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә мөнәсәбәттә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә әлеге карар кабул ителү белән бәйле Учреждениенең гамәлгә кую документларына тиешле үзгәрешләрне керткәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасының тиешле норматив хокукый атларына, аларны әлеге карарның

1 пунктына яраштыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\760.docx